**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Сарлинского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального**
**района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Центральная, д. 68А, село Сарлы,
Азнакаевского муниципального района, 423315
Тел. 36-5-34

Үзәк урам, 68А, Сарлы авылы
Азнакай муниципаль районы, 423315
Тел. 36-5-34

# КАРАР

«15» март 2022 ел, № 1

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының “2021 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында” карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Сарлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл Советының 2012 елның 19 апрелендәге 42 номерлы карары белән кабул ителгән авыл җирлеге халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, халык алдында тыңлаулар үткәрү юлы белән Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын гамәлгә ашыру максатыннан Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының «2020 елда Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында» гы карары проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен халык алдында тыңлаулар үткәрү максатыннын карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының "2021 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында"гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Халык алдында ачык тыңлаулар үткәрү инициаторы - Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге башлыгы.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты-2022 елның 08 апреле 16.00 сәгатьтә;
- үткәрү урыны-Сарлы авылы КФҮ бинасы.

- тикшерелә торган  мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим ителә торган адрес: 423315 ТР, Азнакай районы, Сарлы  авылы, Үзәк урам, 68А.

4. Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының "2021 елда Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" гы карары проекты буенча, гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең норматив-хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокта ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының "2021 елда Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" гы карары проектын Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru) веб-адресы буенча 2022 елның 16 мартыннын да сонга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Сарлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakayevo. tatarstan.ru//  2022 елның 16 мартыннан да соңга калмыйча игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М.Р.Шәрипов